# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

## КАРАР

«03» ноябрь, 2023 ел Иштирәк авылы № 3

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Аулаш авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Иштирәк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2023 елның 18 ноябренә 12.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Аулаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. 2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2024 елда яшәү урыны буенча Иштирәк авыл җирлеге Аулаш авылында территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- юлларны ремонтлау Үзәк урамында.

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Аулаш авылы, Үзәк урам, 67/1 (ФАП бинасы).

4. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Иштирәк авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә (tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Иштирәк авыл җирлеге Башлыгы Г.С. Гарифуллина